**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

« 10 » 02 2025 ел № 6/1

**«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2025 елның 5 декабрендәге 4/4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында » 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» Россия Федерациясе Оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы, авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2025 елның 5 декабрендәге 4/4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 5 пункты «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«окладка 135% күләмендә айлык премия;».

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырып, рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы Д.М.Габделхаева